**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның «16» июленнән №11-80

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2025 елның 29 декабрендәге 5-31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2025 елның 29 декабрендәге 5-31 номерлы карары белән расланган 2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2026 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр исемлеген түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт белән тулыландырырга:

| № т/б | Милек атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйданы, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль | 1141,2 | 2026 елның 3 кварталы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | районы, Яңа Чишмә авылы, Парк урамы, 16 й. адресы буенча урнашкан Гараж-остаханә торак булмаган бина, кадастр номеры 16:31:150106:128, гомуми мәйданы 1141,2 кв.м. һәм 16:31:150106:134 кадастр номерлы җир кишәрлеге, гомуми мәйданы 1346 кв.м. | районы, Яңа Чишмә авылы, Парк урамы, 16 й. | | |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский